# Теркәгечләр

”

**Теркәгечләр – җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне үзара бәйли торган ярдәмче сүз төркеме.**

(Союзы- это вспомагательные части речи, которые соединяют между собой члены предложения и в сложных предложениях простые предложения).

# Теркәгечләр

Тезүче (сочинительные)

Ияртүче (подчинительные)

# Тезүче теркәгечләр

- Җыючы (собирательные):

  һәм, да, дә,та,тә,тагын(снова)

- Каршы куючы (противительные):

  ләкин, ә,тик (лишь), әмма

- Бүлүче (разделительные):

  я, яки, яисә

# Иярт үче теркәгечләр:

Чөнки, әгәр, аеруча, ягъни, шуңа күрә (потому что, если, особенно, поэтому)

- **- Теркәгеч нинди сүз төркеме?**

**(ярдәмче сүз төркеме)**

- **- Алар нәрсәләрне үзара бәйләү өчен кулланылалар?**
- **(Алар җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне бәйләү өчен кулланылалар).**
- **- Сез нинди теркәгечләрне беләсез? Мисаллар әйтегез.**

**(Ә, ләкин, һәм, чөнки һ.б.).**

Уникенче март.

Дүшәмбе көн.

Сыйныф эше.

Теркәгечләр.

# ШИГЫРЬДӘГЕ МИН ҺӘМ СИН АЛМАШЛЫКЛАРЫН ТӨРЛЕ КИЛЕШЛӘРГӘ КУЕП ЯЗАРГА.

| Килешләр | Алмашлыклар |
|---|---|
| Баш килеш | Мин, син |
| Иялек килеше | Минем, синең |
| Юнәлеш килеше | Миңа, сиңа |
| Төшем килеше | Мине, сине |
| Чыгыш килеше | Миннән, синнән |
| Урын-вакыт килеше | Миндә, синдә |

*Казан – борынгы һәм тарихи шәһәр. Мең ел эчендә ул күп вакыйгалар кичергән, ләкин данлы исемен югалтмаган. Башкалабыз Сөембикә манарасы яки Кол Шәриф мәчете белән генә дә горурлана ала.*

# 311 нче күнегү өстендә эшләү.

**а) нокталар урынына тиешле хәрефләрне һәм кушымчаларны куеп дәфтәреңә күчереп яз, кайсы төр төркәгечләр кулланылмаган? Шул теркәгечләр белән, текстны дәвам итеп, бер-ике җөмлә уйлап яз.**

# *Иҗади биремле эш.*

***Нокталар урынына тиешле теркәгечләрне куеп язарга. (карточкаларда эш).***

# САЙЛАНМА ДИКТАНТ

| Тезүче теркәгечләр | | | Ияртүче теркәгечләр |
| --- | --- | --- | --- |
| җыючы | каршы куючы | бүлүче | гүя, чөнки |
| һәм | ләкин, әмма | | |

- - Бүген без нинди теманы өйрәнүне дәвам иттек?
- -Теркәгечләр ничә төркемчәгә бүленәләр?
- - Мәгънә бәйләнеше ягыннан тезүче теркәгеч ничә төргә булена?

# Өй эше бирү

(өч төрле дәрәҗәдәге карточка белән)

- ***1. Тезүче һәм ияртүче теркәгечләр кулланып, «Казаным» темасына хикәя язарга, теркәгечләрнең мәгънә бәйләнешен аңлатырга.***
- ***2. Газета-журналлардан тезүче һәм ияртүче теркәгечләр кергән биш җөмлә сайлап язарга, теркәгечләрнең төркемчәләрен билгеләргә.***
- ***3. Әдәбият дәреслегеннән тезүче һәм ияртүче теркәгечләр кергән биш җөмлә сайлап язарга.***


Игътибарыгыз өчен рәхмәт!
www.blikst.ru